**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в статью 8 Закона Республики Татарстан «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» и Закон Республики Татарстан «Об обеспечении жилыми помещениями детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, и о внесении изменения в статью 8 Закона Республики Татарстан «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
15 февраля 2024 года

## Статья 1

Внести в абзац второй пункта 5 статьи 8 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 12 (II часть), № 12 (III часть); 2005, № 2; 2006, № 2 (I часть); 2007, № 11; 2008, № 5 (I часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2010, № 10 (II часть); 2011, № 8 (I часть), № 10 (I часть); 2012, № 6 (I часть), № 7 (I часть); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 4, № 12 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 44 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 38 (часть I), № 78 (часть I); 2019, № 2 (часть I); 2020, № 57 (часть I), № 87 (часть I); 2021, № 20 (часть I), № 49 (часть I); 2022, № 3 (часть I), № 17 (часть I), № 77 (часть I), № 90 (часть I), № 96 (часть I); 2023, № 92 (часть I), № 95 (часть I) изменение, изложив его в следующей редакции:

«Лица, которые относились к категории детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, лиц из числа детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, и достигли возраста 23 лет, имеют право на однократное предоставление за счет средств бюджета Республики Татарстан выплаты на приобретение благоустроенного жилого помещения в собственность или для полного погашения предоставленного на приобретение жилого помещения кредита (займа) по договору, обязательства заемщика по которому обеспечены ипотекой, в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.».

**Статья 2**

Внести в Закон Республики Татарстан от 12 января 2013 года № 8-ЗРТ «Об обеспечении жилыми помещениями детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, и о внесении изменения в статью 8 Закона Республики Татарстан «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 1 (часть I); 2019, № 19 (часть I); 2020, № 1 (часть I); 2023, № 56 (часть I), № 92 (часть I) следующие изменения:

1) наименование изложить в следующей редакции:

«**О реализации права детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, лиц из их числа на жилое помещение**»;

2) в преамбуле слова «определяет порядок предоставления детям-сиротам и детям, оставшимся без попечения родителей, лицам из числа детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей (далее также – дети-сироты, ребенок-сирота), жилых помещений специализированного жилищного фонда по договорам найма специализированных жилых помещений» заменить словами «регулирует отношения, связанные с реализацией права детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, лиц из числа детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей (далее также – дети-сироты, ребенок-сирота), на жилое помещение»;

3) в части 4 статьи 2 слова «частью $3^1$» заменить словами «пунктом $3^1$»;

4) в абзаце первом части 1 статьи $2^1$ слова «частью 4» заменить словами «пунктом 4»;

5) дополнить статьей $3^1$ следующего содержания:

«Статья $3^1$. **Дополнительные гарантии права на жилое помещение в виде предоставления выплаты на приобретение благоустроенного жилого помещения в собственность или для полного погашения кредита (займа) по договору, обязательства заемщика по которому обеспечены ипотекой**

1. Лица, указанные в пункте 9 статьи 8 Федерального закона, включенные в список в соответствии со статьей 2 настоящего Закона, при наличии совокупности обстоятельств, указанных в пункте 2 статьи $8^1$ Федерального закона, имеют право на однократное предоставление за счет средств бюджета Республики Татарстан выплаты на приобретение благоустроенного жилого помещения в собственность или для полного погашения предоставленного на приобретение жилого помещения кредита (займа) по договору, обязательства заемщика по которому обеспечены ипотекой (далее – выплата).

2. Уполномоченный орган осуществляет контроль за приобретением жилых помещений за счет выплаты, в том числе путем направления и получения межведомственных запросов о соответствии приобретаемого получателем выплаты жилого помещения установленным санитарным и техническим правилам и нормам, иным требованиям законодательства, о наличии или об отсутствии информации о признании данного жилого помещения непригодным для проживания и (или) признании многоквартирного дома, в котором находится данное жилое помещение, аварийным и подлежащим сносу или реконструкции.

3. Предоставление выплаты, в том числе проведение проверки документов, необходимых для перечисления выплаты, перечисление выплаты и контроль за приобретением жилых помещений за счет выплаты осуществляются уполномоченным органом в соответствии с пунктом 8 статьи $8^1$ Федерального закона.

4. Решение о предоставлении выплаты или об отказе в ее предоставлении принимается комиссией, созданной уполномоченным органом (далее – комиссия), в соответствии с порядком, установленным Правительством Российской Федерации, с учетом совокупности обстоятельств, указанных в пункте 2 статьи $8^1$ Федерального закона. Деятельность комиссии осуществляется в соответствии с положением, утвержденным уполномоченным Правительством Российской Федерации федеральным органом исполнительной власти.

5. Право на выплату подтверждается именным документом на приобретение жилого помещения – сертификатом, форма, правила выпуска и реализации которого утверждаются в соответствии с пунктом 11 статьи $8^1$ Федерального закона.

6. Выдача сертификата лицам, указанным в части 1 настоящей статьи, осуществляется уполномоченным органом на основании решения комиссии о предоставлении выплаты.»;

6) статью 5 дополнить частями $5^2$ и $5^3$ следующего содержания:

«$5^2$. Срок действия договора найма специализированного жилого помещения может быть сокращен по инициативе лица, с которым заключен договор найма специализированного жилого помещения, но не более чем на два года, при наличии по состоянию на дату подачи указанным лицом заявления о сокращении срока действия такого договора в уполномоченный орган совокупности обстоятельств, указанных пунктом $6^2$ статьи 8 Федерального закона.

$5^3$. Перечень документов, прилагаемых к заявлению о сокращении срока действия договора найма специализированного жилого помещения, порядок подачи и рассмотрения указанного заявления, порядок направления информации о принятии решения о сокращении срока действия такого договора или об отказе в сокращении срока действия такого договора (в том числе через многофункциональный центр предоставления государственных и муниципальных услуг либо федеральную государственную информационную систему «Единый портал государственных и муниципальных услуг (функций)») утверждаются в соответствии с пунктом $6^3$ статьи 8 Федерального закона.»;

7) статью $5^1$ изложить в следующей редакции:

«Статья $5^1$. **Размещение информации о реализации права детей-сирот на жилое помещение в государственной информационной системе «Единая централизованная цифровая платформа в социальной сфере»**

1. В государственной информационной системе «Единая централизованная цифровая платформа в социальной сфере» подлежит размещению следующая информация:

1) о предоставлении в соответствии с настоящим Законом детям-сиротам жилых помещений специализированного жилищного фонда по договорам найма специализированных жилых помещений;

2) о предоставлении выплаты, в том числе о регистрационном номере сертификата, решении уполномоченного органа о выдаче сертификата, дате выдачи сертификата и дате заключения договора купли-продажи жилого помещения, приобретенного за счет выплаты, размере выплаты, об адресе приобретенного жилого помещения, о дате исключения получателя выплаты из списка.

2. Размещение и получение указанной в части 1 настоящей статьи информации в государственной информационной системе «Единая централизованная цифровая платформа в социальной сфере» осуществляются в соответствии с Федеральным законом от 17 июля 1999 года № 178-ФЗ «О государственной социальной помощи».».

**Статья 3**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

2. Действие положений частей $5^2$ и $5^3$ статьи 5 Закона Республики Татарстан от 12 января 2013 года № 8-ЗРТ «О реализации права детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, лиц из их числа на жилое помещение» распространяется на договоры найма специализированных жилых помещений, заключенные до дня вступления в силу настоящего Закона.

3. Положения пункта 2 части 1 статьи $5^1$ Закона Республики Татарстан от 12 января 2013 года № 8-ЗРТ «О реализации права детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, лиц из их числа на жилое помещение» в части использования государственной информационной системы «Единая централизованная цифровая платформа в социальной сфере» применяются с 1 января 2026 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН · ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
26 февраля 2024 года
№ 4-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 15 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар категориясендә элек булган һәм 23 яшькә җиткән затлар милеккә уңайлы торак урыны сатып алу өчен яисә заемчының йөкләмәләре ипотека белән тәэмин ителгән шартнамә буенча торак урыны сатып алуга бирелгән кредитны (заемны) тулысынча каплау өчен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бер тапкыр түләү алу хокукына ия.».

**2 статья**

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынына хокукын гамәлгә ашыру турында»**;

2) преамбулада «ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга (алга таба шулай ук – ятим балалар, ятим бала) махсуслаштырылган торак фондыннан махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибен билгеле» сүзләрен «ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның (алга таба шулай ук – ятим балалар, ятим бала) торак урынына хокукын гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2 статьяның 4 өлешендә «$3^1$ өлешендә» сүзләрен «$3^1$ пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

4) $2^1$ статьяның 1 өлешендәге беренче абзацында «4 өлешендә» сүзләрен «4 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

5) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ статья өстәргә:

«$3^1$ статья. **Милеккә уңайлы торак урыны сатып алу өчен яисә заемчының йөкләмәләре ипотека белән тәэмин ителгән шартнамә буенча кредитны (заемны) тулысынча каплау өчен түләү бирү рәвешендә торак урынына хокукның өстәмә гарантияләре**

1. Федераль законның 8 статьясындагы 9 пунктында күрсәтелгән һәм әлеге Законның 2 статьясы нигезендә исемлеккә кертелгән затлар, Федераль законның $8^1$ статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән шартларның барысы да булганда, милеккә уңайлы торак урыны сатып алу өчен яисә заемчының йөкләмәләре ипотека

белән тәэмин ителгән шартнамә буенча торак урыны сатып алуга бирелгән кредитны (заемны) тулысынча каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бер тапкыр түләү (алга таба – түләү) алу хокукына ия.

2. Вәкаләтле орган торак урыннарын түләү исәбенә сатып алуны контрольдә тота, ул шул исәптән түләүне алучы тарафыннан сатып алына торган торак урынының билгеләнгән санитария кагыйдәләренә һәм нормаларына, техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүе турында, әлеге торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану һәм (яисә) әлеге торак урыны урнашкан күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану турында мәгълүмат булу яисә булмау хакында ведомствоара гарызнамәләр җибәрү һәм алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

3. Түләүне бирү, шул исәптән түләүне күчерү өчен кирәкле документларны тикшерү, түләүне күчерү һәм түләү исәбенә торак урыннары сатып алуны контрольдә тоту вәкаләтле орган тарафыннан Федераль законның $8^1$ статьясындагы 8 пункты нигезендә башкарыла.

4. Түләүне бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту хакында карар вәкаләтле орган төзегән комиссия (алга таба – комиссия) тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип нигезендә Федераль законның $8^1$ статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән шартларның барысын да исәпкә алып кабул ителә. Комиссия эшчәнлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган нигезләмәгә таянып гамәлгә ашырыла.

5. Түләүне алуга хокук торак урыны сатып алу өчен исемле документ – сертификат белән раслана, аның рәвеше, аны чыгару һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләре Федераль законның $8^1$ статьясындагы 11 пункты нигезендә раслана.

6. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затларга сертификат бирү комиссиянең түләүне бирү турындагы карары нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.»;

б) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле $5^2$ һәм $5^3$ өлешләр өстәргә:

«$5^2$. Махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсенең гамәлдә булу срогы махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсе төзелгән зат тәкъдиме белән иң күбе ике елга кыскартылырга мөмкин, моның өчен күрсәтелгән зат тарафыннан әлеге шартнамәнең гамәлдә булу срогын кыскарту турында вәкаләтле органга гариза бирелгән датага Федераль законның 8 статьясындагы $6^2$ пунктында күрсәтелгән шартларның барысы да булырга тиеш.

$5^3$. Махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсенең гамәлдә булу срогын кыскарту турында гаризага өстәп бирелә торган документлар исемлеге, күрсәтелгән гаризаны тапшыру һәм карау тәртибе, мондый шартнамәнең гамәлдә булу срогын кыскарту турында яисә мондый шартнамәнең гамәлдә булу срогын кыскартудан баш тарту хакында карар кабул итү турындагы мәгълүматны җибәрү тәртибе (шул исәптән күпфункцияле дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзәге йә «Бердәм дәүләт хезмәтләре (функцияләре) һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтү порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша) Федераль законның 8 статьясындагы $6^3$ пункты нигезендә раслана.»;

7) $5^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$5^1$ статья. **«Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында ятим балаларның торак урынына хокукын гамәлгә ашыру турында мәгълүмат урнаштыру**

1. «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында түбәндәге мәгълүмат урнаштырылырга тиеш:

1) әлеге Закон нигезендә ятим балаларга махсуслаштырылган торак фондыннан махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында;

2) түләү бирү турында, шул исәптән сертификатның теркәү номеры, вәкаләтле органның сертификат бирү турындагы карары, сертификатны бирү датасы һәм түләү исәбенә сатып алынган торак урынын сату-алу шартнамәсен төзү датасы, түләүнең күләме, сатып алынган торак урынының адресы, түләү алучыны исемлектән чыгару датасы хакында.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматны «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру һәм алу «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынына хокукын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы $5^2$ һәм $5^3$ өлешләре нигезләмәләренең гамәлдә булуы әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләренә кагыла.

3. «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынына хокукын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $5^1$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезләмәләре «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдалану өлешендә 2026 елның 1 гыйнварыннан кулланыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 февраль
№ 4-ТРЗ